| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» октябрь 2022 ел г. Альметьевск № 2424

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелешен планлаштырып төзүпараметрлары яисә бакча йорты объектын урнаштыру параметрлары һәм мөмкинлеген күрсәтеп, хәбәрнамәдә күрсәтелгән юнәлештә, хәбәрнамәдә каралганча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 маендагы 740 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелешен планлаштырып төзүпараметрлары яисә бакча йорты объектын урнаштыру параметрлары һәм мөмкинлеген күрсәтеп, хәбәрнамәдә күрсәтелгән юнәлештә, хәбәрнамәдә каралганча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 маендагы 740 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

1.5 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүче –дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органга яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органга (дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тыш), яисә «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларга, яисә «Россия Федерациясенең аерым закон актларына

Зак. № 305-2000

үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән экспертларга Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле вәкилләргә яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 19 февралендәге 26-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән оешмаларга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, мөрәҗәгать итүче бердәм гариза бирү юлы белән, берничә дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтү турындагы телдән, язмача яки электрон формада сорау белән мөрәҗәгать итүче физик яисә юридик зат яисә аларның вәкаләтле вәкилләре;

1.5 пунктының 3 абзацында «төзүчеләрнең бөлгенлеге (банкротлыгы) аркасында өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания һәм» сүзләрен ««Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе» һәм» сүзләренә алмаштырырга;

2.5.1 пунктының 1 абзацында «индивидуаль торак төзелеше объектын төзү яисә реконструкцияләү» сүзләрен ««Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү» сүзләренә алмаштырырга;

2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9) пунктча өстәргә:

«9) төзүчегә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51.1 статьясының 7 өлешендәге 2 пунктында һәм 7 өлешендәге 2 пунктында һәм 8 өлешендәге 3 пунктында каралган хәбәрнамәләрне җибәрү ысулы»;

карарга № 1 кушымтасының 3 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 3.0, 3.0.1 пунктлары белән тулыландырырга:

«3.0. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата да.

3.0.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми билгеләре белән берләштерелгән категориягә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата да, билгеләнми.»;

кушымтаны (белешмәне) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кушымта (белешмә)

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәт күрсәтү һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

| Ф.И.О. | Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Косарев Денис | Район башкарма | 39-01-70 | D.Kosarev@tatar.ru |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Васильевич | комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары | | |

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы

| Ф.И.О. | Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Газизова Зөлфия Мурот кызы | бүлек белгече | 39-01-69 | Zulfiya.Gazizova@tatar.ru |
| Зиафетдинова Лилия Хәлим кызы | бүлек белгече | 39-01-69 | Liliya.Ziafutdinova@tatar.ru» |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов